**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1052

г. Казань

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 нче пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1052.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан
Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә (алга таба – учреждениеләр) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү шартларын һәм күләмен билгеләү кагыйдәләрен кертә.

2. Субсидияләр учреждениеләргә учреждениеләрне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләләрен гамәлгә ашыручы (алга таба – гамәлгә куючылар) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары (дәүләт органнары) тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле гамәлгә куючыга учреждениеләрнең түбәндәге чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә:

Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында дәүләт йөкләмәсе нигезендә учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр башкару) белән бәйле норматив чыгымнар составында исәпкә алынмый торган чаралар үткәрүгә;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча дәүләт йөкләмәсе нигезендә учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр башкару) белән бәйле норматив чыгымнар составында исәпкә алынмый торган чаралар үткәрүгә;

учреждениеләрне ябу, үзгәртеп оештыру, учреждениеләр хезмәткәрләренең санын яки штатын киметү белән бәйле чаралар үткәрүгә;

учреждениеләр хезмәткәрләренә дәүләт йөкләмәсен үтәү белән бәйле булмаган акчалата түләүләр гамәлгә ашыруга;

учреждениеләрнең уставларында каралган төп эшчәнлек төрләрен тәэмин итү максатларында, аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәт объектларын сатып алуга;

дәүләт йөкләмәсе нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) финанс чыгымнары нормативына кертелмәгән, учреждениеләргә оператив идарә итү яки түләүсез файдалану хокукында беркетелгән мөлкәтне карап тотуга;

учреждениеләргә оператив идарә итү яки түләүсез файдалану хокукында беркетелгән күчемсез мөлкәткә агымдагы ремонт үткәрүгә;

грантлар бирүгә;

социаль түләүләрне гамәлгә ашыруга;

дәүләт йөкләмәсе нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) норматив чыгымнарга кертелмәгән башка чыгымнарга.

3. Субсидия алу өчен учреждение гамәлгә куючыга түбәндәгеләрне тапшыра:

учреждение тарафыннан ирекле формада төзелгән субсидия бирүгә заявка;

учреждение җитәкчесе раслаган субсидия акчасы исәбеннән гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган чыгымнар сметасы (алга таба – чыгымнар сметасы), чыгымнарның күләмен нигезли торган мәгълүматны (хисаплау формулалары һәм аларны куллану тәртибе, чыгымнар нормативлары, статистика мәгълүматлары, коммерция тәкъдимнәре һәм, субсидия бирү максатларыннан чыгып, башка мәгълүмат) һәм аны алу чыганагын күрсәтеп, чыгымнарның планлаштырылган юнәлешләре калькуляциясен үз эченә алырга тиешле финанс-икътисадый нигезләмне теркәп.

4. Субсидия учреждениегә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган бертип форма буенча әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган көннән соң 10 көн эчендә гамәлгә куючы һәм учреждение арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә.

Субсидия учреждениегә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган аерым шәхси счетка килешүдә күздә тотылган вакыт эчендә күчерелә.

5. Килешү төзүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

чыгымнар сметасы күрсәткечләренең гамәлгә куючыга расланган бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артуы.

Гамәлгә куючының субсидия бирүдән баш тарту турындагы карары учреждениегә әлеге карарны кабул иткән көннән соң ике көн эчендә хат аша җиткерелә.

6. Субсидия күләме гамәлгә куючы тарафыннан чыгымнар сметасы һәм финанс-икътисадый нигезләмә нигезендә гамәлгә куючыга каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

7. Гамәлгә куючы түбәндәге очракларда килешүгә үзгәрешләр кертү юлы белән субсидия күләмен үзгәртергә хокуклы:

субсидия аларны тормышка ашыру өчен бирелә торган максатларны (чараларны, эшләр составын) кирәк булганча корректировкалауны исәпкә алып, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре яки гамәлгә куючыга каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары күләме артуы яки кимүе;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм учреждение тарафыннан нигезләнгән заявка бирү шарты белән өстәмә чыгымнарны гамәлгә ашыруга учреждениенең ихтыяҗы;

учреждение тарафыннан субсидия бирү максатларына ирешүне тәэмин итүгә

чыгымнар күләме буенча килешүдә каралганнан азрак булган очракта, шулай ук учреждениенең нигезсез файдаланылмый калган субсидиясе булуы хакында гамәлгә куючы тарафыннан карар кабул ителгән очракта, әлеге калган акча суммасына субсидия күләмен киметү зарурлыгы;

субсидия бирү буенча чыгым йөкләмәләрен билгели торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү.

8. Учреждение ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10сына кадәр, гамәлгә куючы билгеләгән форма буенча субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында гамәлгә куючыга хисап тапшыра.

9. Агымдагы финанс елында файдаланылмый калган, гамәлгә куючы аларга карата ихтыяҗ булу һәм чираттагы финанс елында шул ук максатларга юнәлтү турында карар кабул итмәгән субсидияләр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.

10. Учреждение субсидия бирү шартларын бозганда, гамәлгә куючының язмача таләбе нигезендә субсидияләр тиешле таләпне алган көннән соң 10 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

11. Учреждениеләрнең субсидия бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрне үтәвен тикшерүдә тоту гамәлгә куючылар һәм вәкаләтле дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___